КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 июль г.Казань № 561

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының беренчел звеносын модернизацияләү» төбәк программасын раслау турында

«Россия Федерациясе сәламәтлек саклау системасының беренчел звеносын модернизацияләү» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының беренчел звеносын модернизацияләү» төбәк программасын (алга таба – төбәк программасы) расларга.
2. Төбәк программасының җаваплы башкаручысы итеп Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин